МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.03.2019 Казан ш. № 141

Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү буенча эш оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 2017 елның 17 августындагы 590 номерлы карарының 2 пунктын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирүгә заявка формасын;

Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә субсидия бирү турында килешү формасын.

2. Инновацион эшчәнлек бүлегенә (Д.И.Луньков) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

юридик затлардан субсидия бирүгә заявкалар кабул итү һәм теркәү;

Тапшырылган документларның һәм алардагы мәгълүматларның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 17 августындагы 590 номерлы карары белән расланган Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә билгеләнгән таләпләргә һәм шартларга тәңгәл килүен тикшерү;

субсидияләр бирү турында юридик затлар белән килешүләр әзерләү һәм төзү;
юридик затлардан субсидиядән файдалану турында хисаплылык җыю.
3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.Р.Киреевага йөкләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы - беренче урынбасар,
Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү
департаменты директоры Р.Р.Сибгатуллин

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2019 елның 25 март № 141
боерыгы
белән расланды

Форма

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы

Заявка
Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирүгә,
20 ____ елга

_______________________________________________
(оешма атамасы, ИНН/КПП)

| № п/п | Чыгымнар юнәлешләре | Сумма (сум.) |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| … | | |
| n | | |

Оешма
җитәкчесе_________________________________________________________________
(вазыйфа, имза, тулы имза)

Оешманың баш
хисапчысы_________________________________________________________________
(имза, тулы имза)
«___»_______________20 ___ ел

Кушымта итеп бирелүче документлар исемлеге:

________________________

________________________

________________________

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2019 елның 25 март № 141
боерыгы
белән расланды

Форма

КИЛЕШҮ
Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабына субсидия бирү турында

Казан ш.
«___»_______ 20___ел №___________

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсе нигезендә субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре җиткерелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы,
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________,
*(юридик зат уставы, ышанычнамә, бүтән документ реквизитлары)* нигезендә эш итеп,
________________________________________________________________________
(вазыйфа атамасы, Ф.И.О.)
йөзендә алга таба "Министрлык" дип аталучы,
бер яктан, һәм
________________________________________________________________________,
*(юридик зат уставы реквизитлары)* нигезендә эш итүче
________________________________________________________________________,
*(юридик зат - субсидия алучы атамасы)*
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
*(вазыйфа атамасы, шулай ук Алучыны тәкъдим итүче зат фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)*
йөзендә, алга таба "Алучы" дип аталучы, икенче яктан, алга таба бергә "Яклар"дип аталучылар, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 17 августындагы 590 номерлы карары нигезендә расланган юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибе (алга таба - Субсидия бирү тәртибе) нигезендә, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеде.

## I. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014-2021 елларга Татарстан Республикасы икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады" дәүләт программасын раслау турында" 2013 елның 31 октябрендәге 823 санлы карары белән расланган "2014-2021 елларга Татарстан Республикасы икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады" дәүләт программасының "2016-2021 елларга Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү" ярдәмче программалары чараларын гамәлгә ашыру кысаларында Алучының Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү белән бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә 20__ елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба - Субсидия) бирү.

1.2. Субсидия Алучы тарафыннан түбәндәге чара(лар)ны гамәлгә ашыру максатларында бирелә:

1.2.1. ________________________________________________________________;

1.2.2. ________________________________________________________________.

1.3. Әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән чара (-лар) Алучы тарафыннан әлеге 1 Килешүнең аерылгысыз өлеше булган техник бирем (1нче кушымта) нигезендә фәнни-тикшеренү эше рәвешендә гамәлгә ашырыла. Фәнни-тикшеренү эшләрен башкару этаплары, эшләре һәм сроклары әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган Эшләр башкаруның календарь планы (2 нче кушымта) белән билгеләнә. Әлеге Килешү буенча фәнни-тикшеренү эшләрен тәмамлау датасы булып Якларның эшләрне тапшыру-кабул итү актын имзалаган дата тора[1].

1.4. Әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән чара Алучы тарафыннан әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган укыту программасы (4нче кушымта) нигезендә гамәлгә ашырыла [2].

1.5. Әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән чара Алучы тарафыннан әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган интеллектуаль милек мәсьәләләре буенча фәнни-техник, икътисадый һәм методик чаралар программасы (6нчы кушымта) нигезендә гамәлгә ашырыла[3].

## II. Субсидия бирүне финанс тәэмин итү

2.1. Субсидия Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак, Икътисад министрлыгына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә, әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга түбәндәге күләмдә бирелә:

БК коды буенча ________ ________ (____________________) сум;
(БК коды) (сүз белән суммасы)

БК коды буенча ________ ________ (____________________) сум;
(БК коды) (сүз белән суммасы)

БК коды буенча ________ ________ (____________________) сум.
(БК коды) (сүз белән суммасы)

2.2. 20__ елга Субсидия күләме _______________ сум тәшкил итә.

2.3. Әлеге Килешүнең аерылгысыз өлешләре булып түбәндәгеләр тора:

Фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга чыгымнар сметасы (3нче кушымта)[4];

Укыту чарасын башкаруга чыгымнар сметасы (5нче кушымта) [5];

Интеллектуаль милек мәсьәләләре буенча фәнни-техник, икътисадый һәм методик чаралар башкаруга чыгымнар сметасы (7нче кушымта)[6].

III. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Субсидия, Алучы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырган очракта, Субсидия бирү тәртибе һәм Министрлыкның 20 _____ елга субсидия бирү турында 20___ елның _______ №____ карары нигезендә бирелә:

3.1.1 Министрлык раслаган форма буенча заявкалар;

3.1.2. чыгымнар күләмен нигезләүче мәгълүмат күрсәтелгән, планлаштырылган чыгымнар юнәлешләре калькуляциясе булган финанс-икътисадый нигезләүне кушымта итеп биреп, әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән Субсидия акчалары хисабына гамәлгә ашырырга ниятләнгән чараларны гамәлгә ашыруга Алучының җитәкчесе раслаган чыгымнар сметасы;

3.1.3 Алучының штат расписаниесе;

3.1.4 Алучының гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр турында документларның күчермәләре;

3.1.5 Алучының Субсидия бирү тәртибенең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә тәңгәл килүе турында Алучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы имзалаган белешмә;

3.1.6. субсидия күчерелә торган исәп-хисап счеты турында белешмә;

3.1.7. Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы "а-д" пунктчаларында күрсәтелгән чараны үткәргән очракта:

3.1.7.1. Алучының Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә, фәнни-техник эшчәнлек нәтиҗәләрен саклау һәм яклауны тәэмин итүгә, патент һәм маркетинг тикшеренүләре, патент, фәнни-тикшеренү һәм технологик экспертизалар үткәрүгә юнәлтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруын раслаучы документлар (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары) күчермәсе;

3.1.7.2. ISO 9001:2008 (ГОСТ ISO 9001:2015) таләпләренә туры килүче сыйфат менеджменты системасы сертификаты күчермәсе;

3.1.7.3. Интеллектуаль милек буенча федераль хезмәтнең (Роспатент) "Федераль сәнәгать милке институты" федераль дәүләт учреждениесе белән хезмәттәшлек турында шартнамә күчермәсе;

3.1.8. Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы "е" пунктчасында күрсәтелгән чараны үткәргән очракта:

3.1.8.1. Алучының укыту эшчәнлеген гамәлгә ашыруын раслаучы документлар (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары) күчермәләре;

Татарстан Республикасында Интеллектуаль милек буенча федераль хезмәтнең (Роспатент) "Федераль сәнәгать милке институты" федераль дәүләт учреждениесенең вәкаләтле (терәк) оешмасы белән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен хокукый саклау һәм куллану мәсьәләләре буенча белемнәр тарату юнәлеше буенча хезмәттәшлек турында шартнамә күчермәсе;

3.2. Субсидия күчерү Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла:

3.2.1. әлеге Килешүнең 8нче кушымтасында билгеләнгән, әлеге Килешүнең

аерылгысыз өлеше булып торган Субсидия күчерүнең план-графигы нигезендә;

3.2.2 Алучының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган лицевой счетына, әлеге Килешүнең ____ бүлегендә күрсәтелгән реквизитлар буенча, Яклар тарафыннан Килешү имзалау көненнән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча.

IV. Якларның үзара хезмәттәшлеге

4.1. Министрлык бурычлы:

4.1.1. Әлеге Килешүнең III бүлеге нигезендә Субсидия бирүне тәэмин итәргә;

4.1.2. Алучы тарафыннан тапшырылган документларны Алучыдан алган көннән соң биш эш көне дәвамында тикшерүне гамәлгә ашырырга;

4.1.3. әлеге Килешүнең 3.2.2 пунктчасы нигезендә күрсәтелгән Алучы счетына субсидия күчерүне тәэмин итәргә;

4.1.4. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган 9нчы кушымтада нәтиҗәлелек күрсәткечләрен билгеләргә.

4.1.5. Алучының әлеге Килешүнең 4.3.6.2 пункты нигезендә тәкъдим ителгән, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган әлеге Килешүгә 10нчы кушымтада билгеләнгән форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләренә ирешү турында хисап нигезендә әлеге Килешүнең 4.1.4. пунктына яраклы рәвештә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүен бәяләүне гамәлгә ашырырга;

4.1.6. планлы һәм (яки) планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән Алучының субсидияләр бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәвен контрольдә тоту:

4.1.6.1. түбәндәгеләр нигезендә Министрлык урнашкан урын буенча:

4.1.6.1.1. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган 11нче кушымтада билгеләнгән форма буенча, әлеге Килешүнең 4.3.6.1 пункты нигезендә тәкъдим ителгән Алучының финанс тәэмин итү чыганагы Субсидия булган чыгымнары турында хисап, аңа чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны раслаучы түбәндәге документларның күчермәләре кушымта итеп бирелә: Алучының вәкаләтле вазыйфаи заты раслаган шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, исәп-хисаплар, счет-фактуралар, башкарылган эшләр актлары;

4.1.6.1.2. әлеге Килешүнең 4.3.7 пункты нигезендә Министрлык соравы буенча Алучы тәкъдим иткән бүтән документлар.

4.1.6.2. Алучы тарафыннан Субсидияне куллану белән бәйле операцияләрнең документаль һәм фактик анализы юлы белән Алучы булган урын буенча;

4.1.7. Министрлык тарафыннан билгеләү яисә дәүләт финанс контроле органыннан Алучының субсидия бирү кагыйдәләре һәм әлеге Килешү нигезендә каралган субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу факты (-лары) турында мәгълүмат алу очрагында, шул исәптән әлеге Килешү нигезендә Алучы тапшырган документларда ялган белешмәләр күрсәтелгән очракта, Алучыга Татарстан Республикасы бюджетына күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда Субсидияне кире кайтаруны тәэмин итү турында таләп җибәрергә;

4.1.8. Алучы әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләренә ирешмәгән очракта, Субсидия бирү

тәртибенең 17 пунктында билгеләнгән күләмдә штраф санкцияләре кулланырга, әлеге карарны кабул итү көненнән алып биш эш көне дәвамында Алучыга мәҗбүри рәвештә хәбәр итәргә.

4.1.9. Алучы тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәрне, документларны һәм башка мәгълүматны, шул исәптән әлеге килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә, аларны алган көннән 10 эш көне дәвамында карарга һәм кабул ителгән Карар турында Алучыга хәбәр итәргә;

4.1.10. Алучыга әлеге Килешүнең 4.4.2 пункты нигезендә Алучы мөрәҗәгате алынганнан соң 5 эш көне дәвамында әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмалар җибәрергә;

4.2. Министрлык хокуклы:

4.2.1. шул исәптән, әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә Алучы юллаган мәгълүмат һәм тәкъдимнәргә яраклы рәвештә, Субсидия күләмен киметүне дә кертеп, Алучы тарафыннан җибәрелгән мәгълүмат һәм тәкъдимнәр нигезендә, шулай ук әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләренең кулланылмаган лимитлары булганда субсидия күләмен арттыруны да кертеп, һәм Алучы әлеге үзгәрешнең финанс-икътисадый нигезләвеннән гыйбарәт мәгълүмат биргән очракта, әлеге Килешүнең шартларын үзгәртү турында карар кабул итәргә;

4.2.2. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә, 20__ елда[7] тотылмаган Субсидия калдыгын әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга 20__ елда[8] юнәлтүгә ихтыяҗ булу яки булмау турында карар кабул итәргә, әлеге Килешүнең 4.3.10 пункты нигезендә, әлеге акчалар бюджет керемена кергән һәм Алучыдан Субсидия калдыгын әлеге Килешүнең 4.3.2 пункты нигезендә күрсәтелгән максатларга юнәлтүдә ихтыяҗны нигезли торган түбәндәге документларны алган көннән башлап 30 эш көненнән соң булмаган вакытта:

4.2.2.1. 20__ елда[8] күрсәтелгән акчаларны кулланмау сәбәбен нигезләп, әлеге Килешүнең 4.1.6.1.1. пунктчасы нигезендә чыгымнар турында хисап;

4.2.2.2. чыгымнар күләмен нигезләүче мәгълүмат күрсәтелгән, планлаштырылган чыгымнар юнәлешләре калькуляциясе булган финанс-икътисадый нигезләүне кушымта итеп биреп, әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән, 20__ елда[7] кулланылмаган Субсидия акчалары хисабына 20__ елда[8] гамәлгә ашырырга ниятләнгән чараларны гамәлгә ашыруга Алучының җитәкчесе раслаган чыгымнар сметасы;

4.2.3. Министрлык билгеләгән яисә дәүләт финанс контроле органыннан Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә каралган Субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу факты (-лары) турында мәгълүмат алган, шул исәптән әлеге Килешү нигезендә Алучы биргән документларда ялган белешмәләр күрсәтелгән очракта, күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәнчегә кадәр, карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча мәҗбүри рәвештә Алучыга хәбәр итеп, Субсидия бирүне туктатып торырга.

4.2.4. Алучының, әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә, Субсидия бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен Алучыдан кирәкле документларны һәм мәгълүматны соратып алырга;

4.2.5. Алучы Субсидияне, Субсидия калдыгын Татарстан Республикасы бюджетына кайтаруның Министрлык яки дәүләт финанс контроле органы таләбендә билгеләнгән срогын бозган очракта, Субсидияне, Субсидия калдыгын кайтару вакыты чыкканнан соң җиде эш көне дәвамында, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәҗбүри тәртиптә Субсидияне, Субсидия калдыгын түләттерү буенча чаралар күрергә.

4.3. Алучы бурычлы:

4.3.1. Министрлыкка әлеге Килешүнең 3.1 пункты нигезендә документлар тапшырырга;

4.3.2. Министрлыкка әлеге Килешүнең 4.2.2.1, 4.2.2.2 пунктчалары нигезендә (кирәк булган очракта) хисап елыннан соң 15 эш көне дәвамында документлар тапшырырга;

4.3.3. Субсидия бирү тәртибендә билгеләнгән операцияләрдән тыш, Субсидия хисабына чит ил валютасын сатып алмаска;

4.3.4. Субсидия хисабына гамәлгә ашырылган операцияләрнең аналитик исәбен алып барырга;

4.3.5. әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә Министрлык билгеләгән нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләренә ирешүне тәэмин итәргә;

4.3.6. Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшырырга:

4.3.6.1. хисап елыннан соң килгән унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге Килешүнең 4.1.6.1.1 пункты нигезендә Алучының финанс тәэмин итү чыганагы Субсидия булган чыгымнары турында хисап;

4.3.6.2. 4.3.6.1. хисап елыннан соң килгән ун эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге Килешүнең 4.1.5 пункты нигезендә нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләренә ирешү турында хисап;

4.3.7. әлеге Килешүнең 4.2.4 пункты нигезендә Субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны әлеге гарызнамәне алган көннән соң биш эш көне эчендә Министрлык соравы буенча җибәрергә;

4.3.8. Министрлыктан әлеге Килешүнең 4.1.7 пункты нигезендә таләп алынган очракта:

4.3.8.1. күрсәтелгән таләптә билгеләнгән срокларда субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу факт(лар)ын юкка чыгарырга;

4.3.8.2. Татарстан Республикасы бюджетына әлеге таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокта Субсидияне кайтарырга;

4.3.9. Министрлык тарафыннан Алучыга карата әлеге Килешүнең 4.1.8 пункты нигезендә штраф санкцияләрен куллану турында карар кабул ителгән очракта, штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамәдә билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы бюджетына акчаларны кайтарырга;

4.3.10. 20__ елда[8] кулланылмаган Субсидия калдыгын хисап елыннан соң килүче беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджетына кайтарырга;

4.3.11. әлеге Килешү нигезендә Министрлыкка тапшырыла торган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итәргә;

4.3.12. Россия Федерациясендә гражданлык билгеләнешендәге фәнни-

тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләрнең дәүләти исәбе турында Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган таләпләрне үз вакытында үтәргә[9];

4.3.13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында гражданлык билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләренең дәүләти исәбе һәм аларны саклауның бердәм системасы турында нигезләмәне раслау турында" 2010 елның 12 мартындагы 133 санлы карарында каралган таләпләрне үз вакытында үтәргә[10].

4.4. Алучы хокуклы:

4.4.1. әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертү турында Министрлыкка тәкъдимнәр җибәрергә, шул исәптән, әлеге үзгәрешнең финанс-икътисадый нигезләве булган мәгълүматны кушымта итеп биреп, Субсидия күләмен үзгәртү кирәк булган очракта;

4.4.2. әлеге Килешү үтәлеше белән бәйле аңлатмалар алу максатыннан Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә;

4.4.3. 20__ елда[7] әлеге Килешү нигезендә алынган Субсидиянең кулланылмаган калдыгын (булган очракта) әлеге Килешүнең 4.2.2. пункты нигезендә Министрлык тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга яраклы рәвештә түләүләрне гамәлгә ашыруга җибәрергә.

## V. Якларның интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен куллануга бәйле хокуклары һәм бурычлары [11].

5.1. Алучы тарафыннан 1.2 пунктчасында күрсәтелгән чараны фәнни-тикшеренү эше рәвешендә гамәлгә ашырган вакытта әлеге Килешү кысаларында булдырылган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә махсус хокукларга Алучы ия.

Әлеге Килешүнең 5.1 пункты нигезендә, Алучы фәнни-тикшеренү эшләре тәмамланганнан соң алты ай дәвамында фәнни-тикшеренү эшләре нәтиҗәләренә махсус хокукларны беркетүне тәэмин итмәгән очракта, Министрлык фәнни-тикшеренү эшләре нәтиҗәләренә махсус хокукларны үзенә беркетергә хокуклы.

5.2. Хокукларны беркеткәндә фәнни-тикшеренү эшләре нәтиҗәләрен хокукый саклауны тәэмин итү һәм үз көчендә калдыру буенча чыгымнар Алучы хисабына башкарыла. Алучы бу максатлар өчен әлеге Килешү буенча бирелгән акчаларны кулланырга хокуклы.

5.3. Министрлык таләбе буенча Алучы Министрлыкка махсус хокук гамәлдә булган вакытка дәүләт ихтыяҗлары өчен әлеге Килешү кысаларында булдырылган тиешле махсус хокук объектын куллануга түләүсез гади (махсус булмаган) лицензияне күрсәтергә бурычлы.

## VI. Якларның җаваплылыгы

6.1. Әлеге Килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тота.

## VII. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Яклар арасында әлеге Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле килеп туган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, тиешле беркетмәләрне яки башка документларны рәсмиләштерү юлы белән сөйләшүләр уздыру юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешмәгән очракта, Яклар арасында бәхәсләр, Россия Федерациясе законнары нигезендә, суд тәртибендә хәл ителә.

7.2. Әлеге Килешү һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затлар тарафыннан кул куелган көннән үз көченә керә, әмма әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын җиткерүдән дә иртәрәк түгел һәм яклар тарафыннан әлеге Килешү буенча үз бурычларын тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

7.3. Әлеге Килешүне үзгәртү, шул исәптән әлеге килешүнең 4.2.1 пункты нигезләмәләренә яраклы рәвештә, Яклар килешүе буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган әлеге Килешүгә өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

7.4. Әлеге Килешү түбәндәге очракларда өзелергә тиеш:

7.4.1. Алучы эшчәнлеген яңадан оештыру яки туктату;

7.4.2. Алучының Субсидия бирү тәртибе һәм әлеге Килешү белән билгеләнгән Субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозуы.

7.5. Алучы әлеге Килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, Министрлык әлеге Килешүне берьяклы тәртиптә өзә.

7.6. Әлеге Килешү яклар тарафыннан ике нөсхәдә кәгазь документ рәвешендә, һәр як өчен бер нөсхәдә төзелгән.

## VIII. Якларның түләү реквизитлары

| "Министрлык" | "Алучы" |
|---|---|
| Атамасы___________________________<br><br>ОГРН, ОКТМО | Алучының атамасы<br><br>ОГРН, ОКТМО |
| Урнашкан урыны: | Урнашкан урыны: |
| ИНН/КПП | ИНН/КПП |
| Түләү реквизитлары:<br><br>Россия Банкы учрежениесе атамасы, БИК<br>Исәп-хисап счеты<br>Татарстан Республикасы Финанс | Түләү реквизитлары:<br><br>Россия Банкы учрежениесе атамасы, БИК<br>Исәп-хисап счеты |

| | |
|---|---|
| министрлыгында лицевой счет | |

VIII. Якларның Имзалары

| "Министрлык"<br>________________________________ | "Алучы" |
|---|---|
| ___________/_________________<br>(имза) (ФИА) | ___________/_________________<br>(имза) (ФИА) |

[1] Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы а), б), в) пунктчаларында күрсәтелгән чаралар гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла;

[2] Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы е) пунктчасында күрсәтелгән чара гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла;

[3] Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы д) пунктчасында күрсәтелгән чара гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла;

[4] Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы а), б), в), г) пунктчаларында күрсәтелгән чаралар гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла;

[5] Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы е) пунктчасында күрсәтелгән чара гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла;

[6]Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы д) пунктчасында күрсәтелгән чара гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла;

[7] Субсидия бирү елыннан соң килүче ел күрсәтелә;

[8] Субсидия бирү елы күрсәтелә;

[9] Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы а), б), в), г) пунктчаларында күрсәтелгән чаралар гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла;

[10] Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы а), б), в), г) пунктчаларында күрсәтелгән чаралар гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла;

[11] Алучы тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең 3 пунктындагы а), б), в), г) пунктчаларында күрсәтелгән чаралар гамәлгә ашырылган очракта күздә тотыла .

Килешүгә
1нче кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

Фәнни-тикшеренү эшен башкаруга
**техник бирем**

______________________________________________________
(чараның аталышы)

1. Заказчы: Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы
2. Башкаручы (Алучы): ___________________________________________.
3. Эшләрне башкару урыны: Башкаручы урнашкан урын буенча.
4. Эшләрне башкару срогы: дәүләт контракты төзү датасынан алып ______ елның 31 декабренә кадәр.
5. Эшләрне башкару өчен нигез:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014-2021 елларга Татарстан Республикасы икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады" Дәүләт программасын раслау турында" 2013 елның 31 октябрендәге 823 санлы карары белән расланган "2014-2021 елларга Татарстан Республикасы икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады" Дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында" һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2013-2020 елларга Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү" Озак вакытлы максатчан программасын раслау турында" 2013 елның 15 гыйнварындагы 11 санлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында" 2018 елның 27 июнендәге 533 санлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 2017 елның 17 августындагы 590 номерлы карары;

- Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанс тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү.

6. Эшләрнең максаты
7. Эшләрнең эчтәлеге

| №№ пп. | Эшләрнең эчтәлеге | Нәтиҗәне тәкъдим итү формасы |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4… | | |

8. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре

| №№ пп. | Чараның аталышы | Күрсәткечнең аталышы | Күрсәткечнең план билгесе | Күрсәткечкә ирешү ниятләнгән вакыт |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

9. Хисаплылык

Эшләрне үткәрү нәтиҗәләре фәнни-тикшеренү эше турында йомгаклау хисабы рәвешендә тапшырыла. Фәнни-тикшеренү эше турында йомгаклау хисабы "Мәгълүмат, китапханә һәм нәшрият эше буенча стандартлар системасы. Фәнни-тикшеренү эше турында хисап. Рәсмиләштерү структурасы һәм кагыйдәләре" ГОСТ 7.32-2001 таләпләре нигезендә төсле басма рәвешендә рәсмиләштерелгән һәм беркетелгән документ рәвешендә тапшырыла. (60 биттән **ким түгел**, шрифт Times New Roman, кегль 13, интервал – 1,5, формат А4, кәгазьнең тыгызлыгы 80 г/м$^2$ **ким түгел**, кәгазьнең төсе ак). Башкаручы хисап материалларын кәгазь туплагычта Заказчы адресына тапшыра: Татарстан Республикасы, Казан ш., Мәскәү ур., 55 йорт.

| | |
|---|---|
| Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы | Алучының башкаручысы<br>(вазыйфа, ФИА, телефон) |
| ______________________________ | ______________________________ |
| (имза) | (имза) |
| «__» __________ 20__ ел | «__» __________ 20__ ел |

| "Министрлык" ______________________________ | "Алучы" ______________________________ |
|---|---|
| __________/__________________<br>(имза) (ФИА) | __________/ __________________<br>(имза) (ФИА) |

Килешүгә
2нче кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

Фәнни-тикшеренү эшен башкаруның
**календарь планы:**

_______________________________________________
(чараның аталышы)

| Этап номеры | Этапның аталышы, этап эшләре эчтәлеге | Башкару этабында эшкәртелә торган документлар исемлеге | Хисап документларын тапшыру датасы |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3… | | | |
| | **Фәнни-тикшеренү эше турында йомгаклау хисабын әзерләү һәм килештерү** | **Фәнни-тикшеренү эше турында йомгаклау хисабы** | |

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы

_____________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

Алучының башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

_____________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

| "Министрлык"<br>______________________________ | "Алучы"<br>______________________________ |
|---|---|
| ___________/___________________<br>(имза) (ФИА) | ___________/ ___________________<br>(имза) (ФИА) |

Килешүгә
3нче кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

Фәнни-тикшеренү эшен башкаруга
**чыгымнар сметасы**

_______________________________________________

(чараның аталышы)

| **Күрсәткечнең аталышы** | **Юл коды** | **КОСГУ буенча код** | **Өст. ЭК буенча код** | **Сумма, сум.** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |
| 3… | | | | |
| Барлыгы | | | | |

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы

_______________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

Алучының башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

_______________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

| "Министрлык"<br>______________________________ | "Алучы"<br>______________________________ |
|---|---|
| ___________/__________________<br>(имза) (ФИА) | ___________/ __________________<br>(имза) (ФИА) |

Килешүгә
4нче кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

# Укыту программасы

___________________________________________________
Программаның аталышы

| № п/п | **Хезмәтләргә таләпләр параметрлары** | **Хезмәтләргә таләпләр** |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3… | | |

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы

_________________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

Алучының башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

_________________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

| "Министрлык" ________________________________ | "Алучы" ______________________________ |
|---|---|
| ____________/___________________ (имза) (ФИА) | ____________/ ___________________ (имза) (ФИА) |

Килешүгә
5нче кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

Укыту чараларын башкаруга
**чыгымнар сметасы**

_______________________________________________
(чараның аталышы)

| **Күрсәткечнең аталышы** | **Юл код** | **КОСГУ буенча код** | **Өст. Эк буенча код** | **Сумма, сум.** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |
| 3… | | | | |
| Барлыгы | | | | |

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы

Алучының башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

_______________________________________

_______________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

(имза)

«__» __________ 20__ ел

| "Министрлык"<br>______________________________ | "Алучы"<br>______________________________ |
|---|---|
| ___________/___________________<br>(имза) (ФИА) | ___________/___________________<br>(имза) (ФИА) |

Килешүгә
6нчы кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

# Интеллектуаль милек мәсьәләләре буенча фәнни-техник, икътисадый һәм методик чаралар программасы (форум, симпозиум, конференция, семинар, күргәзмә, конкурс)

______________________________________________
(чараның аталышы)

| № п/п | Хезмәтләргә таләпләр параметрлары | Хезмәтләргә таләпләр |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3… | | |

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы

______________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

Алучының Башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

______________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

| "Министрлык" ______________________________ | "Алучы" ______________________________ |
|---|---|
| ____________/__________________<br>(имза) (ФИА) | ____________/ ____________________<br>(имза) (ФИА) |

Килешүгә
7нче кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

Интеллектуаль милек мәсьәләләре буенча фәнни-техник, икътисадый һәм методик чаралар (форум, симпозиум, конференция, семинар, күргәзмә, конкурс) уздыруга **чыгымнар сметасы**

_______________________________________________
(чараның аталышы)

| **Күрсәткечнең аталышы** | **Юл коды** | **КОСГУ буенча код** | **Өст.ЭК буенча код** | **Сумма, сум.** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |
| 3… | | | | |
| Барлыгы | | | | |

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы

_______________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

Алучының башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

_______________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

| "Министрлык"<br>_______________________ | "Алучы"<br>_______________________ |
|---|---|
| __________/________________<br>(имза) (ФИА) | __________/ ________________<br>(имза) (ФИА) |

Килешүгә
8нче кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

## Субсидия күчерү графигы

| № п/п | Чараның аталышы | Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча код (Субсидия бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары буенча) [1] | | | | Субсидия күчерү сроклары | Күчерелергә тиешле сумма, сумнарда |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | бүлек коды | бүлек, бүлекчә | максат чан статья | чыгымнар төре | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | | | | | | | |
| | | | | | | КБК бунча барлыгы | |
| | | | | | | Чара буенча барлыгы | |
| | | | | | | Барлыгы | |

[1] Килешүнең 2.1 пункты нигезендә күрсәтелә

Инновацион эшчәнлек
бүлеге башлыгы

Алучының башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

_______________________________________ _______________________________________

(имза) (имза)

«__» ___________ 20__ ел «__» ___________ 20__ ел

| "Министрлык"<br>________________________________ | "Алучы"<br>____________________________ |
|---|---|
| ____________/____________________<br>(имза) (ФИА) | ____________/ ____________________<br>(имза) (ФИА) |

Килешүгә
9нчы кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

НӘТИҖӘЛЕЛЕК КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ

| № п/п | Күрсәткечнең аталышы | Чараның аталышы | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәткечнең план билгесе | Күрсәткечкә ирешү ниятләнгән вакыт |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Атамасы | Код | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы

____________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

Алучының Башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

____________________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

| "Министрлык" ______________________________ | "Алучы" ______________________________ |
|---|---|
| ___________/__________________ (имза) (ФИА) | ___________/ __________________ (имза) (ФИА) |

Килешүгә
10нчы кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

РАСЛЫЙМ
Министр урынбасары
_____________________
«___» _____________ 20___ ел

Нәтиҗәлелек күрсәткечләре билгеләренә ирешү турында
ХИСАП

20__ елның __ _________ торышы буенча

Алучының атамасы _______________________________________________
Кабатлану вакыты: ______________________

| N п/п | Күрсәткечнең аталышы [1] | Чараның аталышы | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәткечнең план билгесе [2] | Хисап датасы торышына ирешелгән күрсәткеч билгесе | Планны үтәү проценты | Тайпылыш сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Атамасы | Код | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

[1] Әлеге таблицада күрсәтелгән күрсәткеч аталышы килешүгә 2нче кушымтаның 2 графасында күрсәтелгән күрсәткеч аталышына тәңгәл килергә тиеш.
[2] Әлеге таблицада күрсәтелгән күрсәткечнең план билгесе килешүгә 2нче кушымтаның 6 графасында күрсәтелгән план билгесенә тәңгәл килергә тиеш.

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы
____________________________________
(имза)
«__» __________ 20__ ел

Алучының Җитәкчесе
(вәкаләтле зат)
________________________________________
(имза)
«__» __________ 20__ ел

Алучының башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)
__________/ ____________
(имза) (ФИА)

«___» ____________ 20___ ел

| "Министрлык" ______________________________ | "Алучы" ___________________________ |
|---|---|
| __________/_________________ (имза) (ФИА) | ___________/ __________________ (имза) (ФИА) |

Килешүгә
11нче кушымта
№ _______ «__» _______ 20__ ел

РАСЛЫЙМ
Министр урынбасары
____________________
«___» ____________ 20___ ел

Хисап
финанс тәэмин итү чыганагы Субсидия булган
чыгымнар турында
20__ елның «__» _________ [1]

Алучының атамасы ______________________________________________________
Кабатлану вакыты: Елына 1 тапкыр
Үлчәү берәмлеге сум (икенче унарлы билгегә кадәр төгәллек белән)

| Күрсәткечнең аталышы | Юл коды[2] | Субсидияне тоту юнәлеше коды | Сумма | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Хисап чоры | ел башыннан арта баручы нәтиҗә белән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Ел башына субсидия калдыгы, барлыгы: | 100 | Х | | |
| шул исәптән:<br>расланган ихтыяҗлы | 110 | Х | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиешле | 120 | | | |
| Акчалар керде, барлыгы: | 200 | Х | | |
| шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан | 210 | Х | | |
| узган елларның дебиторлык бурычы | 220 | Х | | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барлыгы: | 300 | | | |
| шул исәптән:<br>Персоналга түләү, барлыгы: | 310 | 0100 | | |
| шул исәптән: | | | | |
| Эшләр һәм хезмәтләр сатып алу: | 320 | 0200 | | |
| шул исәптән: | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Башкарылмаган активлар, матди булмаган активлар, матди запаслар һәм төп чаралар сатып алу, барлыгы: | 330 | 0300 | | |
| шул исәптән: | | | | |
| Устав (берләштерелгән) капиталына кертемнәр сыйфатында акчалар, башка оешма милкенә кертемнәр күчерү (әгәр максатчан акчалар бирү тәртибен җайга салучы норматив хокукый актларның нигезләмәләрендә аларны күрсәтелгән оешмага күчерү мөмкинлеге каралса), барлыгы: | 340 | 0420 | | |
| шул исәптән: | | | | |
| Исәплрдән чыккан: | 350 | 0610 | | |
| шул исәптән: | | | | |
| Акчаларны депозитларга, бүтән финанс инструмнтларына урнаштыру максатларында күчерү (әгәр федераль законнарда максатчан акчаларны бу рәвешчә күчерү каралган булса), барлыгы: | 360 | 0620 | | |
| шул исәптән: | | | | |
| Россия Феерациясе бюджеты бюджет системаларына салымнар, җыемнар һәм бүтән түләүләрне түләү, барлыгы: | 370 | 0810 | | |
| шул исәптән: | | | | |
| Бүтән түләүләр, барлыгы: | 380 | 0820 | | |
| шул исәптән: | | | | |
| Йомгаклау исәп-хисаплары буенча түләүләр, барлыгы: | 390 | | | |
| шул исәптән: | | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылган, барлыгы: | 400 | X | | |
| шул исәптән:<br>максатчан билгеләнеш буенча тотылмаганнары | 410 | X | | |
| штраф санкцияләре куллану | 420 | X | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| нәтиҗәсендә | | | | |
| Хисап чоры ахырына Субсидия калдыгы, барлыгы: | 500 | X | | |
| шул исәптән:<br>шул ук максатларга юнәлтүдә таләп ителә | 510 | X | | |
| кайтарылырга тиеш | 520 | X | | |

[1] Әлеге хисап финанс елы башыннан арта баручы нәтиҗә белән төзелә.
[2] Субсидия бирү Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә казначылык озата баруы кысаларында гамәлгә ашырылса, 100 - 220, 500 - 520 юллар әлеге хисапта күздә тотылмый.

Кушымта: чараларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны раслаучы документларның күчермәләре: вәкаләтле вазыйфаи зат раслаган шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счетлар, сфет-фактуралар, башкарылган эшләр актлары 1 нөсхәдә __ биттә.

Инновацион эшчәнлек бүлеге башлыгы

______________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

Алучының башкаручысы
(вәкаләтле зат)

______________________________

(имза)

«__» __________ 20__ ел

Алучының башкаручысы
(вазыйфа, ФИА, телефон)

__________/ __________
(имза) (ФИА)

| "Министрлык" | "Алучы" |
|---|---|
| ______________________ | ______________________ |
| __________/__________<br>(имза) (ФИА) | __________/ __________<br>(имза) (ФИА) |